Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге Советының егерме алтынчы утырышы

Колай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

29 декабрь, 2022 ел

№ 65

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башлыгы, Колай авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында

«Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында» 2021 елның 9 апрелендәге 19 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге Советы карарына (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2022 елның 10 октябрендәге 56 номерлы Колай авыл җирлеге Советы карары белән расланган үзгәрешләр белән) (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның 1.1 пунктчасында «17944» санын «19039» санына алмаштырырга;

1.2 пунктның 1.2 пунктчасында «11958» санын «12688» саннарына алмаштырырга;

1.3 пунктның 1.3 пунктындагы җиденче абзацында «1 процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 Кушымтаның икенче абзацында «7,71» санын «10,36» санына алмаштырырга;

1.5. 6 кушымтаның 3 пунктындагы 3.1 пунктчасында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 8 кушымтаның 6 пунктында «бер процент» сүзләрен «18 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Колай авыл җирлеге башлыгы Н.В.Поповская